КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 май г.Казань № 340

Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын чыгару белән бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел,

30 декабрь, 1006 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, 1121 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 15 сентябрь, 828 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 2 октябрь, 891 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 май, 340 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау өчен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында тиешле финанс елына субсидия бирү өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – Агентлык) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия турындагы белешмәләр (мәгълүматлар) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында («Бюджет» бүлегендә) урнаштырыла.

4. Татарстан Республикасы законнар җыелмасын бастырып чыгаруның сарыф ителгән акчаны каплау максаты белән субсидия бирелә торган чыгымнары юнәлешләре:

штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләү һәм аларның хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертем-

нәрен, дәүләт пошлиналарын, башка мәҗбүри бүлеп алып калынган суммаларны һәм түләүләрне Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләү;

типография һәм полиграфия хезмәтләре күрсәтү, алып килеп бирү (транспортлау) (мәҗбүри нөсхәсен кертеп) чыгымнары өчен түләү;

бүлмәләрне арендалау, техник чаралар сатып алу, коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре күрсәтү, программа тәэминаты (бухгалтерлык программалары, вируска каршы программалар, электрон хисаплылык) чыгымнары, белешмә-мәгълүмат базаларын яңарту, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану өчен түләү;

интернет-сайтны карап тоту һәм аның эшләвен тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен түләү;

канцелярия һәм чыгым материаллары, инвентарь, офис техникасы сатып алу, аңа хезмәт күрсәтү (ремонтлау) чыгымнары;

авторлык һәм чиктәш хокуклар буенча түләүләр (архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдалану чыгымнарыннан тыш);

редакция чыгымнары;

банк хезмәтләре күрсәтү өчен түләү.

5. Бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Агентлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы. Шул ук вакытта штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең субсидия исәбеннән түләнергә тиешле хезмәтенә түләү чыгымнары суммалары, хезмәткәрләрнең исәпләнгән саныннан, исәпләнгән вазыйфаи окладлардан, вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүләрдән, стимуллаштыра торган түләүләрдән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып, расланган штат расписаниесе нигезендә оешманың локаль норматив актлары белән билгеләнә.

6. Субсидия Агентлык белән оешма арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә. Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Агентлыкка киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

оешманың Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы.

Кирәк булуга карап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

7. Оешма килешү төзергә планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

оешманың салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

оешманың Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмаска тиеш;

оешма үзгәртеп оештыру (оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә тиеш, оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;

оешма чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләт һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аларның теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше аларның устав (җыелма) капиталында барысы бергә 50 проценттан арткан Россия юридик заты булмаска тиеш;

оешма бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

8. Субсидия алу өчен оешма Агентлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Агентлык тарафыннан расланган форма буенча чыгымнарның исәп-хисаплары һәм нигезләүләре теркәлгән субсидия бирү турында гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләрен;

оешма җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен;

субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счеты реквизитларын күрсәтеп, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган, оешма мөһере белән расланган белешмә кагазен (ирекле формада);

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган, оешма мөһере белән расланган чыгымнар сметасын;

оешманың штат расписаниесен;

субсидия бирелә торган, фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документларның: шартнамәләр, накладнойлар, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары, эш хакыннан акча тотып калу һәм акча исәпләү җыелмасы күчермәләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында оешма җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазен (ирекле формада).

Документлар оешма тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһере белән расланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми. Кәгазьдә бирелгән гаризаның һәр бите тегелгән, номерланган, оешманың вәкаләтле заты тарафыннан имза куелган булырга тиеш.

Бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен оешма Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

9. Оешма үз теләге белән Агентлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау турында салым органы биргән белешмә кәгазен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Оешма тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Агентлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Агентлык эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә оешма тарафыннан тапшырылган документларны терки һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Оешмага субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

оешма тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Агентлык бу турыда оешмага эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә хәбәр итә.

11. Агентлык, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.

12. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – күрсәтелгән ай эчендә субсидия бирелгән айга кадәрге айның соңгы көненә туры килә торган датага «Татарстан Республикасы законнар җыентыгы» журналының кимендә сигез чыгарылышын бастырып чыгару.

13. Оешма, субсидия бирелгән айдан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Агентлыкка килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасы буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.

14. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, шулай ук субсидияләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия оешма тарафыннан Агентлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

15. Оешма тарафыннан бу Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Агентлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

16. Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары оешма тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Субсидия акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Агентлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---